КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 ноябрь г.Казань № 1015

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче, 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче; 2017 ел, 26 май, 310 нчы; 2018 ел, 27 ноябрь, 1060 нчы; 2020 ел, 12 март, 186 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт органы яки граждан тарафыннан пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә түләү билгеләү өчен тапшырылган документлар кергәндә Министрлык 30 көн эчендә:

тапшырылган документларны рәсмиләштерү дөреслеген тикшерүне гамәлгә ашыра;

бу Кагыйдәләрнең 2.3 нче пунктында күрсәтелгән пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә түләү билгеләү өчен документларның булуын тикшерә;

дөрес булмаган мәгълүматларның булуына тапшырылган документларны тикшерүне гамәлгә ашыра һәм тиешле чаралар күрә;

дәүләт вазыйфасын биләү чорларын һәм (яки) дәүләт хезмәте стажын раслау кирәк булган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан һәм (яки) пенсиягә (тиешле еллар өчен пенсиягә) өстәмә түләүне билгеләүне дәгъва итүче гражданнардан тиешле документларны соратып ала;

ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән электрон формада, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар ала;

пенсиягә өстәмә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсия) билгеләү турында яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

4.3 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин